Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Мамык авыл җирлеге Мамык авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
КАРАР

«30» ноябрь 2021 ел № 3

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2021 елның 22 ноябрендә узган: «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Мамык авыл җирлеге территориясендә яшәүче һәр балигъ булган кешедән, 1 гр инвалидлардан, балачак инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, яшәү урыны буенча теркәлгән, әмма яшәмәгән гражданнарнардан тыш, 2022 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Торак пункт чикләрендәге юлларны ремонтлау һәм карап тоту;

- Су белән тәэмин итү чыганакларына норматив таләпләрне тәэмин итү буенча эшләр үткәрү:

- Урамнарны яктыртуны оештыруны тәэмин итү өчен эшләр һәм хезмәтләр, товарлар сатып алу;

- Мамык авылында ике җәяүлеләр күперен ремонтлау» мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:
җыенда катнашучы сайлау хокукына ия булган гражданнар исемлегенә 779 кеше кертелгән, җыенда тавыш бирүдә 403 кеше катнашты.
Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
«ӘЙЕ» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 331 кеше тавыш бирде;
«ЮК» позициясе өчен җыенның 72 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:
1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Мамык авыл җирлеге Мамык авылы торак пунктында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.
2. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Мамык авыл җирлеге территориясендә яшәүче һәр балигъ булган кешедән, 1 гр инвалидлардан, балачак инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, яшәү урыны буенча теркәлгән, әмма яшәмәгән гражданнарнардан тыш, 2022 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Торак пункт чикләрендәге юлларны ремонтлау һәм карап тоту;

- Су белән тәэмин итү чыганакларына норматив таләпләрне тәэмин итү буенча эшләр үткәрү:

- Урамнарны яктыртуны оештыруны тәэмин итү өчен эшләр һәм хезмәтләр, товарлар сатып алу;

- Мамык авылында ике җәяүлеләр күперен ремонтлау» мәсьәләсе буенча кабул ителгән карарны таныырга.

3. Халык җыены нәтиҗәләрен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Мамык авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Мамык авыл җирлеге тарафыннан кабул ителгән әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче: В.В. Рыжков

Мамык авыл җирлеге башлыгы В.В. Рыжков